Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
«Кармыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
ГРАЖДАННАРЫ ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге
составына керүче Кармыш торак пунктында

07 ноябрь 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш.

Алынган чараларны җибәрергә:

- Кармыш, Яшәүче торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юл-урам челтәрендәге юл кырыйларын норматив хәлгә китерү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
- Кармыш, Яшәүче торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Кармыш авылы торак пунктларында урам юл челтәрендә чокырларны ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне(хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу
- Кармыш, Яшәүче торак пунктларында скважиналарны лицензияләү, суга экспертиза һәм анализ өчен түләү
- Кармыш, Яшәүче торак пунктларында зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, коймаларны (урнаштыру) ремонтлау һәм буяу, чүп савытларын урнаштыру, коры-сарыдан чистарту, керү юлларын, сукмакларны төзекләндерү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документлары өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу һәм башкарылган эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- 2015 ел өчен үзара салым акчаларының 148010 сум күләмендә калдыкларын куллану.

Халык җыенында рәислек итүче
Кармыш авыл җирлеге башлыгы: И.И.Фәтхетдинов